ГЛАВА КАВЗИЯКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘҮҖИЯК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 14 ноябре № 5

Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Түбән Бикмет авылында 2023 елда үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. 2022 елның 19 ноябрендә 09.00 сәгатькә Түбән Бикмет авылының фельдшер-акушерлык пункты бинасында: ТР, Сарман муниципаль районы, Түбән Бикмәт авылы, Чапаев урамы, 42а, Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Түбән Бикмәт авылында 2023 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2023 елда Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлеге Түбән Бикмәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, һәм вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән киләсе эш:

1) Түбән Бикмет торак пунктында вак таш түшәмәләрне ремонтлау (вак таш ташу).

"ӘЙЕ " " ЮК?».

3. Әлеге карарны Кәүҗияк авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәүҗияк Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы Ф. Ә. Хөснетдинов